ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ

КАРАР

16.11. 2023 ел №2

2024 елга

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлегенең Монай авылында
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, кертергә.
2. Алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

Контейнер мәйданчыгы урнаштыру һәм контейнерлар сатып алу;
- Фекаль насос сатып алу;
- Урам яктырткычларын сатып алу;
- Акустик җиһазлар сатып алу;
- Төзүчеләр, Монтажчылар урамында юлны ремонтлау;
- Вак таш сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Монай авылы мәгълүмат такталарында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыены рәисе,
Тихоново авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кириллов